*Февраль 2019*

# Гимназия сулышы №3

***25 нче гимназия укучылары газетасы***

**Гыйнвар – февраль аралыгында гимназиядә хәрби –патриотик айлык чаралары булып узды. Безнең фоторепортаж шул чаралар турында.**



19.02.2019

Актлар залы 7-8 сыйныф укучылары белән шыгрым тулы. Бүген биредә Әфганстаннан совет гаскәрләрен чыгаруның 30 еллыгына карата армия җырлары конкурсы үтә. Һәр сыйныф презентация әзерләгән, сугыш җырларын өйрәнгән. Чарада катнашкан әфган сугышы ветераны Джураев Эльдар Сәет улы укучыларның ныклы әзерлекле булуын, тарихка карата ихтирамлы булуларын әйтеп үтте. 7 а сыйныфы укучылары башкарган « Ак кошлар» җыры залда утыручы һәр кешегә нык тәэсир итте һәм беренче урынга лаек булды. Садриева Эльмира

22.02.2019

Спорт залында төз сафларга тезелгән 9-11 сыйныф укучылары дулкынлану белән смотр башлануын көтәләр. Алар ай буена стройда атлап йөрү күнегүләренә

өйрәнделәр. Бүген иң осталарны билгеләячәкләр. Ә жюрида кемнәр соң? Гимназиянең ОБЖ һәм физкультура укытучысы Мәрданшин И.М., армия хезмәтен үткәндә Сириядә сугышчан хәрәкәттә катнашкан , гимназиядә укыган Хисаметдинов Илнур һәм гимназиянең укыту эшләре буенча директор урынбасары Гарипова Р.Р. иң осталарны ачыкладылар.



Смотрда катнашучыларга нинди таләпләр куелды соң? Сафта тигез итеп бер тактка атлау, кием матурлыгы, командирларның дөрес команда бирүе. Миңа калса , барлык класслар да яхшы әзерлек күрсәтте. Нәтиҗәдә, 11а сыйныфы беренче урынга лаек булды. 11 б һәм 9 б сыйныфлары



икенче,өченче урыннарны бүлештеләр. Ә иң « Яхшы взвод командиры» исеменә 10 сыйныф укучысы Вәлиев Айнур лаек булды. Чын егетләрчә, булдыра Айнур ! Якупова Гүзәл

**Беләбез һәм горурланабыз!**

Мәрданшин Илнур Мулланур улы Түбән Кама районының Түбән Уратма авылы егете. Мәктәпне тәмамлагач Алабуга педагогия институтында укып, «Физкультура һәм ОБЖ укытучысы»

белгечлеген ала. Аннары Алтай өлкәсендә артиллерия гаскәрләрендә хәрби хезмәттә була.



Инде берничә ел дәвамында Мәрданшин И.М.гимназиядә хәрби-патриотик эшне алып бара. Февральдә шәһәр буенча башлангыч сыйныфлар арасында сафта атлау смотры булып үтте. Илнур Мулланур улы әзерләгән 4 сыйныф взводы беренче урынга лаек булды. Ел саен уздырыла торган «Аҗаган» хәрби-спорты уенында («Зарница») быел гимназия командасы икенче урынны алды. Илнур Мулланур улы аеруча Матвеева Полинаны (8 в), Фәйзуллин Айнурны (7 в), Павлов Глебны (8 в) винтовкадан төз атучылар дип әйтте. Мәрданшин И.М. кебек җаваплы, таләпчән, оста оештыручы укытучы булганда патриотик-тәрбия тиешле дәрәҗәдә булачак, дияргә нигез бар. Хәйруллина Диләрә

**Актуаль интервьюлар**

Фазлыев Раил 6 б сыйныфында укый. Ул2016-17 уку елы нәтиҗәләре буенча «Гимназиянең иң яхшы укучысы» титулына һәм исемле стипендиягә лаек булган иде. Быелгы уку елында Раил фәннәр буенча олимпиадаларда сынатмады. Аңа берничә сорау бирдем.



***-Мин быел инглиз теле буенча Бөтенроссия олимпиадасының республика этабында призёр булдым. Тарих буенча фәннәр олимпиадасының муниципаль этабында призёр, җәмгыять белеме буенча шулай ук муниципаль этапта җиңүче булдым.***

–Раил,син буш вакытыңны ничек үткәрәсең?

***-Беренче сыйныфтан бирле "Аллегро"бию түгәрәгенә йөрим. Тагын "Декоратив эшләнмәләр"түгәрәгенә йөрим. Агачтан төрле әйберләр ясарга яратам.***

–Раил, сиңа укуда яңа уңышлар телибез!

-Уңышка ничек ирешергә? Шул сорау белән 7 г сыйныфы укучысы Сөләйманов Әдилгә мөрәҗәгать иттек.

Ул уку алдынгысы, технология буенча Бөтенроссия олимпиадасының муниципаль этабы җиңүчесе һәм шул ук фәннән республика этабында призёр булуга иреште.

***–Мин вакытымны максатчан файдаланам. Модельләр ясарга яратам. Технология укытучысы Попов А.И. җитәкчелегендәге "Судомоделирование"түгәрәгенә йөрим.***



***Проект эше белән фәнни конференциядә катнаштым һәи икенче урын алдым.***

“Әдил- җаваплы, эзләнүчән, тырыш укучы,- ди аның турында укытучысы Попов А.И. Интервьюларны Бакирова Алия язып алды.



**Сөйләшсәк тә төрле телләрдә …**



21нче февраль - Халыкара туган тел көне. Бераз гына бәйрәм тарихына тукталыйк әле. Халакара туган тел көнен билгеләп үтү инициативасы белән Бангладеш республикасы чыга. Анда 1957 елның 21нче февралендә, туган телдә белем алу хокукын даулап биш студент һәлак була. 2000нче елда Берләшкән Милләтләр Оешмасы ЮНЕСКО инициативасын хуплап, күптеллелекне яклау йөзеннән 21нче февральне “Халыкара туган тел көне”итеп үткәрү турында карар кабул итте. Безнең гимназиядә Туган тел көнен зурлап бәйрәм иттек.    Бездә 1245 укучы белем ала . Алар рус, татар, чуваш, казах, удмурт, башкорт һәм башка милләттән. Актлар залында башкорт,  инглиз, татар, чуваш телләрендә 4-7 сыйныф укучылары шигырьләр сөйләделәр. «Аллегро» бию ансамбле башкарган  Идел буе тугандаш  халыкларының дәртле  биюләрен

гимназия укучылары һәм килгән кунаклар көчле алкышладылар. 4 сыйныф укучылары курайда татар, рус, башкорт көйләрен оста башкардылар. 7 д сыйныфы укучылары һәм укытучылар ансамбле башкаруында моңлы татар җырларын да һәркем яратып тыңлады.
Чарага чакырылган кунаклар исеменнән «Кама таңнары» әдәби иҗат берләшмәсе әгъзасы, язучы Рәмзия Вәлиева чыгыш ясады. Ул залда утыручыларны Туган тел көне белән котлады һәм яңа язган шигырен сөйләде.
Минемчә, бу бәйрәмдә катнашучы һәркемнең күңелен бер уй биләгәндер: ярый әле, төрле милләт вәкилләре дус, тату булган Татарстанда яшибез!

Качаева Диана



**2019 ел Россидә Владимир Путин указы нигезендә Театр елы дип игълан ителде. Шулай ук Татарстанда да Театр елы-на карата төрле чаралар үткәрелә. Ә шәһәребезнең Туфан Миңнуллин исемендәге татар драма театрында күптән көтелгән капиталь ремонт эшләре башланды. Яңартылган бинада тамашачылар өчен ике тамаша залы, артистлар өчен уңайлы грим бүлмәләре, заманча зур сәхнә булачак.**

## Татарча спектакль карадык



Куптән түгел без-бер төркем 4-5 сыйныф укучылары шәһәрнең Халык иҗаты йортында «Өрә белмәгән көчек» спектаклен карадык. Аның эчтәлеге болай: йорт хуҗасының улы табып кайткан кечкенә көчек өрә белми. Кәҗә бәтие дә, Сарык бәрәне дә бу күренешкә аптырасалар да, Акбай белән дуслашалар. Ишегалдында уйнап-көлеп яшиләр. Ләкин караңгы төндә ишегалдына Бүре килеп керә дә, Кәҗә бәтиен урманга алып китә. Акбай үзенең туган телен белми шул, шуңа күрә , Галине ярдәмгә чакыра алмый…Шушы кимчелек аркасында дуслар Кәҗә бәтиеннән аерыла…Әкиятнең ахырында дуслык җиңеп чыга, әлбәттә.




Бу спектакль туган телгә мәхәббәт, дуслык, тугрылык, батырлык кебек мөһим төшенчәләр турында сөйли. Безгә Казан курчак театры спектакле бик ошады.
Гыйльманова Алия

## Гимназиядә Май чабу бәйрәме

Май чабу үсеп килүче буынны тәрбияләүдә әһәмияткә ия бәйрәм. Бу бәйрәмне руслар гына түгел, татарлар да үз итте. Гимназиядә үткәрелгән

бәйрәмне оештыручы Чурашова Л.А. һәм Родионов Н.А.традициядән читкә китмәделәр.



«Күңелле Карагод» ансамбленың дәртле җырлары, төрле күмәк уеннар, тәмле коймаклар бәйрәмне тагын да ямьләндерде. 1-4 сыйныф укучыларына бәйрәм бик ошады. Ячменева Анастасия




**Безнең якын дуслар**

Шул исемдәге фотокүргәзмәдә дистәләгән йорт хайваннарының фотолары урын алды. Алар гимназия укучыларының песиләре, этләре, ташбака һәм попугайлары - самими җан ияләре үзләренең хуҗаларын бернигә карамыйча яраталар. Күргәзмәгә рәхим итегез, дуслар! Вахапова Рената

## “ШАЯН - ТВ” КАРА – БУЛЫРСЫҢ ИҢ ШӘП БАЛА!

“Шаян - ТВ” каналы ТНВда 1 февральдән бирле эшли инде. Телеканалның Shayantv.ru дип исемләнгән сайты эшли башлады. Сайтка килеп керү белән үк без татар мохитенә эләгәбез. Сайтта онлайн режимда “Шаян-ТВ”ны да карап булачак. Каналда 20 дән артык тапшыру күрсәтелә. Алар арасында тәрҗемә ителгәннәре дә бар, каналның иҗат төркеме тарафыннан эшләнгәннәре дә шактый. “Шаян - ТВ”ның көндәлек эше балаларның татарча сөйләм телен камилләштерүгә, мультфильм, тапшырулар аша туган телгә кызыксындыру тудыруга юнәлтелгән. “Шаян-ТВ”ны бергәләп карыйк!

Проект җитәкчесе Шарапова Н.Н.
Редактор Якупова Гүзәл